# Исәнлек - зур байлык

Рамил Чурагулов сүзләре

Фәнир Галимов көе




1

Бармак кына авыртса да
Күңел төшә, кәеф юк.
Исәнлекнең кадерен белеп,
Шөкер итеп яшәик.

2

Тау хәтле байлыгың булып,
Исәнлегең булмаса.
Йөзеңнән төс, тәннән дәрман,
Өеңнән нурлар кача.

*Кушымта:*

Байлык нәрсә?! "Җилгә оча".
Диләр: "Байлык – бер айлык".
Исән булсаң, мал табыла,
Исәнлек – ул зур байлык.

3

Сорасалар хәлләремне,
"Барсы да яхшы", диям.
Зарланмыйм мин, уфтанмыйм мин
"Булганына шөкер", итәм.

*Бетерү өчен:* Исәнлекнең кадерен белеп,
Шөкер итеп яшәик!